**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТ АРСТ АН**
422615, с. Чирпы, ул. Заводская, д.22
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422615, Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 2-91-45

**2023 елның 15 декабре** **49 номер**

# КАРАР

**«Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 35 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 35 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 **2 пунктның 2.1 пунктчасының «в» абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннарын һәм инвалидларын;»

2. Әлеге карарның нигезләмәләренең гамәлдә булуы, 2023 елдан башлап салым чорлары өчен җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Чирпы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

.

**Башлык-Татарстан  Республикасы**
**Лаеш  муниципаль  районы Чирпы**
**авыл  җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы                                    Р.В.Мышева**